**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 ноябрендәге 4897 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең балалар музыка, сәнгать, хореография, спорт мәктәпләрендә, югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен алуга конкурсны популярлаштыруга, катнашучылар саны артуга бәйле рәвештә, шулай ук кадрлар үзгәрешен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең балалар музыка, сәнгать, хореография, спорт мәктәпләрендә, югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«Казан шәһәренең балалар музыка, рәсем сәнгате, спорт, хореография мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә, Казан шәһәренең югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»;

1.2. 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучылары, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучылары арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс турында нигезләмә (3 номерлы кушымта);

1.3. 3 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.4. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы карарының 3 номерлы кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 ноябрендәге
4897 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучылары, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучылары арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучылары, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучылары арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс аеруча сәләтле балаларга ярдәм итү, балалар музыка һәм сәнгать мәктәпләре укучыларының сәләтләрен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе (алга таба – Мәдәният идарәсе) тарафыннан ел саен үткәрелә.

1.2. Балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучылары өчен 25 000 сумлык 15 исемле стипендия гамәлгә куела.

1.3. Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучысы өчен 25 000 сум күләмендә 1 исемле стипендия гамәлгә куела.

1.4. Исемле стипендияләр ел саен ноябрь – декабрьдә бирелә.

1.5. Исемле стипендия Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате, сәнгать мәктәбе, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучысына тапшырылырга мөмкин. Исемле стипендия бер катнашучыга укуның бөтен чорында кимендә бер тапкыр бирелә.

## II. Стипендия бирүгә тәкъдим итү тәртибе

2.1. Конкурста Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате, сәнгать мәктәпләре, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучылары катнаша ала.

2.2. Укучыларны Конкурска чыгару хокукы Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате, сәнгать мәктәпләре директорларына, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе директорына бирелә.

2.3. Исемле стипендияләрне алуга дәгъва кылучыларның алдагы уку елы өчен билгеләре «бик яхшы» (75 проценттан ким түгел) һәм «яхшы» булырга тиеш.

2.4. Конкурста катнашу өчен мәктәп директорлары ел саен агымдагы елның 20 маена кадәр Мәдәният идарәсенә kultura.kazan@tatar.ru почтасына электрон формада бер PDF файлында түбәндәге файлларны җибәрергә тиешләр:

- исемле стипендия алуга дәгъва кылучы турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, ае, елы, уку урыны, белгечлеге, укытучысы, ел дәвамында ирешкән уңышлары (конкурсларда, конференцияләрдә, күргәзмәләрдә катнашу), йорт адресы, телефоны, паспорт яки туу турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры һәм иминиятләштерү таныклыгы күчермәсе) белән мәктәптән үтенечнамә;

- мәктәпнең педагоглар советы карарыннан өземтә;

- Казан музыка училищесының, Казан сәнгать училищесының, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең, Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбенең ким дигәндә ике белгеченнән бәяләмә.

2.5. Ел саен конкурс комиссиясе Конкурста катнашучыларны – балалар музыка мәктәпләре, сәнгать мәктәпләре, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучыларын, агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, тыңлаулар уздыра. Комиссия Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен бирү буенча иҗтимагый совет составыннан төзелә (конкурс турындагы нигезләмәнең1 номерлы кушымтасы).

2.6. Катнашучы программасы төрле характердагы һәм төрле жанрдагы ике әсәрдән гыйбарәт булырга тиеш, гомуми хронометражы 10 минуттан артмаска тиеш. Һәр әсәр өчен иң югары бәя – 10 балл.

2.7. Бәяләү критерийлары булып торалар: профессиональлек һәм башкару осталыгы, программаның катлаулылык дәрәҗәсе, музыкаль эчтәлекне ачу, сәхнә

осталыгы һәм музыкаль номерны тәкъдир итү (Конкурс турындагы нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасы).

2.8. Конкурста катнашучыларның – балалар рәсем сәнгате мәктәпләре, сәнгать мәктәпләренең рәсем сәнгате бүлекләре укучыларының эшләрен карау агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча уздырыла.

2.9. Рәсем сәнгатенең һәм техникасының төрле юнәлешләрендә художество осталыгы дәрәҗәсе, образлы эчтәлекне, теманың актуальлеген бирү осталыгы, чикләнгән вакыт эчендә биремне башкару сыйфаты бәяләү критерийлары булып тора (Конкурс турында нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасы).

## III. Иҗтимагый совет төзү, документларны карап тикшерү, стипендияләр билгеләү һәм бирү тәртибе

3.1. Иҗтимагый совет Мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы, профильле махсус урта һәм югары уку йортлары вәкилләре, шәһәр методик берләшмәләре рәисләре, Казан шәһәренең әйдәп баручы сәнгать эшлеклеләре составыннан төзелә (алга таба – иҗтимагый совет).

3.2. Иҗтимагый совет тапшырылган документларга экспертиза үткәрә һәм стипендияләр бирү турында соңгы карарны кабул итә.

3.3. Иҗтимагый совет утырышын үткәрү һәм Казан шәһәре Мэры премиясен бирү турында йомгаклау карарын чыгару агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча башкарылырга тиеш.

3.4. Иҗтимагый совет утырышы, әгәр анда расланган составның кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

3.5. Утырышта иҗтимагый совет рәисе яки иҗтимагый совет әгъзаларының берсе булмаган очракта, утырышта аның вазифаларын башкаручы хезмәткәр катнаша.

3.6. Иҗтимагый совет карары тереләй тыңлау / карау өчен алынган баллар суммасына һәм кандидатлар портфолиосы конкурсына нигезләнә. Тавышлар тигез булганда, тереләй музыкаль тыңлау/сәнгатьчә карауны бәяләү нәтиҗәләре, шул исәптән иҗтимагый совет составының өстәмә бонус баллы бирү турында коллегиаль карары өстенлек булып тора.

3.7. Иҗтимагый совет карарлары яңадан карап тикшерелергә тиеш түгел. Конкурс комиссиясенең баллар белән арадаш беркетмәләре бастырып чыгарылмый.

3.8. Стипендиатларга агымдагы елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча Казан шәһәре Мэрының махсус дипломнары һәм исемле стипендияләре тапшырыла.

3.9. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләре, күрсәтелгән банк реквизитларына күчерү юлы белән, бер тапкыр бирелә.

3.10. Конкурс комиссиясе түбәндәге очракларда премия бирүдән баш тартырга хокуклы:

- түбән һөнәри әзерлек һәм конкурсның турыдан-туры катнашу этабында (музыкаль тыңлау/сәнгати карау) балларның җитәрлек булмавы;

- конкурс документларының (кандидатның портфолиосы) эчтәлеге һәм бизәлеше Конкурс турындагы нигезләмәнең 2.1-2.4 пунктларына туры килми.

________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәдәният идарәсе карамагындагы
балалар музыка, рәсем сәнгате һәм
сәнгать мәктәпләре укучылары,
Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт
консерваториясе каршындагы Урта
махсус музыка мәктәбе укучылары
арасында Казан шәһәре Мэрының
исемле стипендиясен алуга конкурс
турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучыларына, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучыларына Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен бирү буенча иҗтимагый совет составы**

| | |
|---|---|
| Г.Р.Сәгыйтова | совет рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| А.И.Абзалов | совет рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| Совет әгъзалары: | |
| А.Ә.Җаппаров | «И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном мәгариф урта һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| О.А.Гыйльметдинова | «Н.И.Фешин исемендәге Казан рәсем сәнгате училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Д.Б.Маршанский | Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан консерваториясе каршындагы Урта |

| | |
|---|---|
| | махсус музыка мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| А.Ә.Ураскузин | Казан шәһәренең «4 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| Е.А.Борминская | Казан шәһәренең «15 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| А.Р.Садриева | Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәдәният идарәсенең мәдәниятне үстерү һәм чаралар оештыру бүлеге башлыгы урынбасары |

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм сәнгать мәктәпләре укучылары, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбе укучылары арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(формалар)

**Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алу өчен**
**Конкурста катнашучыларны – музыка мәктәбе укучыларын тыңлауны бәяләү бите**

| **№** | **Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, белгечлеге, туган көне, сыйныфы** | **Башкарыла торган программа** | **1 нче әсәр өчен бәя:**<br>- профессиональлек һәм башкару осталыгы,<br>- программаның катлаулылык дәрәҗәсе,<br>- музыкаль эчтәлекне ачу,<br>- сәхнә осталыгы һәм музыкаль номерны тәкъдир итү<br>(иң күбе 10 балл) | **2 нче әсәр өчен бәя:**<br>- профессиональлек һәм башкару осталыгы,<br>- программаның катлаулылык дәрәҗәсе,<br>- музыкаль эчтәлекне ачу,<br>- сәхнә осталыгы һәм музыкаль номерны тәкъдир итү<br>(иң күбе 10 балл) | **Барлыгы** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

**Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алу өчен**
**Конкурста катнашучыларны – рәсем сәнгате мәктәбе укучыларын тыңлауны бәяләү бите**

| № | Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, яше | Туган көне, сыйныфы | **Эшләрне карау** Критерийлар: башкару техникасы, образлы эчтәлекне бирә белү, теманың актуальлеге | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Рәсем** (иң күбе 10 балл) | **Рәсем сәнгате** (иң күбе 10 балл) | **Композиция** (иң күбе 10 балл) | **Декоратив-гамәли сәнгать/Дизайн** (иң күбе 10 балл) | **Эскизлар** (иң күбе 10 балл) | **Рәсем буенча турыдан-туры катнашу конкурсы** (биремне чикләнгән вакытта үтәү сыйфаты) (иң күбе 10 балл) | **БАРЛЫГЫ (**уртача арифм. эшләрне карау буенча + рәсем буенча конкурс – иң күбе 20 балл) |
| 1 | | | | | | | | | |